ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 август 2017 ел № 4916

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/8 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибен кушымтада каралганча расларга
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 23 августындагы
4916 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә
алу, күчерү, саклау, утильләштерү тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнар тормышына куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсуслаштырылган һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулык китерә, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм ишегалды территорияләрен һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләре (алга таба – Төзекләндерү кагыйдәләре) таләпләрен бозып урнаштырылган урыннарны җыештыруны кыенлаштыра торган ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төп төшенчәләр:

хуҗасыз транспорт чарасы – хуҗасы булмаган яки хуҗасы билгесез булган һәм суд карары буенча хуҗасыз дип танылган транспорт чарасы. Андый транспорт чарасының төп билгеләре булып түбәндәгеләр санала: аның ЮХИДИ органнарының махсуслаштырылган исәбендә тормавы, дәүләти теркәлү билгесе булмау һәм транспорт чарасын эксплуатацияләүне тыючы күренеп торган төзексезлекләре булу;

ташландык транспорт чарасы – милек хокукыннан баш тарту максатында аның хуҗасы тарафыннан калдырылган транспорт чарасы, шул исәптән, файдалануда булмавының күренеп торган билгеләре булу (тыны чыккан шиннар, ватылган тәрәзәләр, ачык ишекләр һәм башка формада комплектлаштыру таралган очраклар). Андый транспорт чарасының өстәмә билгеләре булып түбәндәгеләр санала: транспорт чарасын эксплуатацияләүне тыючы күренеп торган төзексезлекләре булу, әлеге күрсәтелгән транспорт чарасының аның өчен билгеләнгән һәм (яки) Төзекләндерү кагыйдәләрен бозып куелган урыннарда булуы;

махсуслаштырылган автомобильләр кую урыны – табып китерелгән ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын саклау өчен билгеләнгән, махсус җиһазландырылган һәм саклана торган мәйданчык;

махсуслаштырылган оешма – «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» (алга таба – Башкарма комитет) МКУ белән муниципаль контракт (килешү) нигезендә транспорт чараларын махсуслаштырылган автомобильләр кую урынына алып бару, махсуслаштырылган автомобильләр кую урыннарында саклау, утильләштерү

эшләрен гамәлгә ашыручы юридик яки физик затлар (шәхси эшмәкәр).

Махсуслаштырылган оешманы сайлау сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарга нигезләнеп башкарыла.

3. Ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү буенча эшләрне оештыру Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының район Хакимиятләре (алга таба – район Хакимияте) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү буенча чыгымнар, аларга муниципаль милек хокукы танылганнан соң, җирле бюджет хисабына каплана.

Ташландык транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү буенча чыгымнар транспорт чарасы милекчесе хисабына каплана.

## 2 бүлек. Ташландык транспорт чарасын ачыклау һәм күчерү эшен оештыру

4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташланганлык билгеләре булган транспорт чараларын ачыклау Башкарма комитетының район Хакимиятләре вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан, аларның вәкаләтләренә туры китерен, Яр Чаллы шәһәренең тиешле район территориясен тикшергән вакытта, шулай ук түбәндәге нигездә гамәлгә ашырыла:

1) Башкарма комитеттан, Яр Чаллы шәһәренең контрольлек итү, күзәтчелек һәм хокук саклау органнарыннан, дәүләт Хакимияте органнарыннан алынган мәгълүматлар;

2) гражданнар, шәхси эшмәкәрләр, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләр;

3) массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» челтәреннән алынган мәгълүматлар;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмати системасын эшләтү кысаларында дәүләт Хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарында гражданнарның үзара берлектә электрон эшләве турында» 2012 елның 10 августындагы 676 нчы карары нигезендәге белдерү хатлары (заявкалары);

5) башка мәгълүмат чыганаклары.

Алынган мәгълүмат Башкарма комитетның тиешле район Хакимияте территориясен тикшерү буенча Комиссиясе тарафыннан, ул район Хакимиятенә кергәннән соң, өч эш көне эчендә тикшерелә.

Территорияне тикшерү буенча Комиссияләр район Хакимиятләрендә төзелә (алга таба – Комиссия), составы Башкарма комитетның тиешле районның Хакимият Башлыгы боерыгы белән раслана.

5. Тикшерүләр нәтиҗәсендә Комиссия тарафыннан әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча акт төзелә.

6. Ташландык транспорт чарасының алдагы пыяласына, ул булмаган очракта, башка күренә торган урынга транспорт чарасы хуҗасының 14 эш көне эчендә аны ремонтлау, саклау яки транспорт чараларын кую өчен билгеләнгән урыннарга күчереп куярга тиешлеген күрсәткән таләп беркетелә, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында каралганча.

7. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән срок тулганнан соң, 4 нче кушымта формасы буенча транспорт чарасын кабаттан тикшерү акты төзелә һәм район Хакимиятенең вазыйфаи затлары ике эш көне эчендә транспорт чарасының хуҗасы турында мәгълүмат барлыгы хакында Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы идарәсе органнарына (алга таба – Яр Чаллы шәһәре буенча ЭЭМИ) запрос юллый.

8. Әгәр Яр Чаллы шәһәре буенча ЭЭМИ да транспорт чарасының хуҗасы турында мәгълүмат булмаса, аны күчерү әлеге Тәртипнең 14-16 пунктларында каралганча башкарыла.

9. Әгәр Яр Чаллы шәһәре буенча ЭЭМИ га транспорт чарасының хуҗасы турында мәгълүмат бирелгән булса, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары ике эш көне эчендә ташландык транспорт чарасы хуҗасының соңгы яшәү урыны адресына заказлы хат белән, транспорт чарасын аны ремонтлау, саклау яки транспорт чаралары кую өчен билгеләнгән урыннарга транспортировкалау (күчерү) кирәклеге таләбен куеп, белдерү хаты җибәрә. Таләп формасы – әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасында.

10. Транспорт чарасы хуҗасына транспорт чарасын күчерү таләбе белән хәбәр бирүнең датасы булып почта бүлегенең транспорт чарасын күчерү таләбе җибәрелү турында белдерүле заказлы хатның кире кайткан датасы санала (адресатның алудан баш тартуы, әлеге адрес буенча адресатның булмавы, саклау срогы чыгу һ.б.).

11. Ташландык транспорт чарасының хуҗасы, аңа карата күрелгән әлеге чараларга да карамастан, аны ремонтлау, саклау яки транспорт чаралары кую өчен билгеләнгән урыннарга күчермәгән очракта, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары өч эш көне эчендә ташландык транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчереп кую турында Башкарма комитетның карар проектын әзерли һәм бер эш көне эчендә аны Башкарма комитетка юллый.

## 3 бүлек. Хуҗасыз транспорт чарасын ачыклау һәм күчерү эшен оештыру

12. Транспорт чарасында дәүләт номеры булмаган, шулай ук кузов номеры турында күренеп торган мәгълүмат булмаган очракта, ташландык транспорт чарасы табылган вакыттан алып өч эш көне эчендә Комиссия тикшерү үткәрә, аның нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы формасы буенча акт төзелә.

13. Ташландык транспорт чарасының алдагы пыяласына, ул булмаган очракта, башка күренә торган урынга транспорт чарасы хуҗасының 14 эш көне эчендә аны ремонтлау, саклау яки транспорт чараларын куеп тору өчен билгеләнгән урыннарга күчереп куярга тиешлеген күрсәткән таләп беркетелә (2 нче кушымта нигезендә).

14. Әгәр хуҗасыз транспорт чарасы әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән срокта алынмаса, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары «Челнинские известия» газетасының якын көннәрдә чыгасы санына транспорт чарасын күчерү турындагы таләпнең басылып чыгуын тәэмин итә (аның кайда торуын һәм характеристикаларын күрсәтеп).

15. Транспорт чарасының булырга мөмкин хуҗасына хәбәр итү датасы дип транспорт чарасын күчерү таләбе «Челнинские известия» газетасында басылып чыккан дата санала.

16. Хуҗасыз транспорт чарасының хуҗасы ачыкланмаган, аңа карата күрелгән әлеге чараларга да карамастан, аны ремонтлау, саклау яки транспорт чаралары кую өчен билгеләнгән урыннарга күчермәгән очракта, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары өч эш көне эчендә ташландык транспорт чарасын махсуслаштырылган урынга күчереп кую турында Башкарма комитетның карар проектын әзерли һәм, килештерү өчен, бер эш көне эчендә аны Башкарма комитетка юллый.

## 4 бүлек. Хуҗасыз һәм ташландык транспорт чараларын күчерү тәртибе

### Ташландык яки хуҗасызлык билгеләре булган транспорт чараларын исәпкә алу.

17. Башкарма комитет биш эш көне эчендә хуҗасыз яки ташландык транспорт чарасын махсуслаштырылган кую урыны территориясенә күчерү турында карар кабул итә (алга таба – карар) һәм карарның күчермәсен бер эш көне эчендә транспорт чарасы табылган урын буенча район Хакимиятенә җибәрә.

18. Район Хакимиятенең вазыйфаи затлары бер эш көне эчендә махсуслаштырылган оешмаларга (идарәче оешма, йорт милекчеләре ширкәте вәкилләренә) транспорт чараларын күчереп кую датасы турында хәбәр итә.

Ташландык (хуҗасыз) транспорт чарасы билгеләнгән датада һәм вакытта Комиссия һәм махсуслаштырылган оешма тарафыннан кабаттан тикшерелә һәм 4 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча акт төзелә, фотосурәт төшерелә.

Транспорт чарасы күп фатирлы йорт территориясендә табылган очракта, кабаттан тикшерү идарәче оешма, йорт милекчеләре ширкәте вәкилләре катнашында үткәрелә.

4 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча төзелгән акт, кул куелганнан соң, ташландык (хуҗасыз) транспорт чарасы кабул итү-тапшыру акты нигезендә, җаваплы саклауга махсуслаштырылган оешмага бирелә.

Ташландык (хужасыз) транспорт чарасы кабул итү-тапшыру акты тапшыручы як сыйфатында – Комиссиянең, ә кабул итүче як сыйфатында махсуслаштырылган оешманың җаваплы заты тарафыннан имзалана.

19. Транспорт чарасын югалткан яки күчерү, шулай ук төяү-бушату эшләрен тиешенчә үтәмәү сәбәпле, аның хуҗасына зыян китергән өчен җаваплылыкны махсуслаштырылган оешма үз өстенә ала.

20. Ташландык яки хуҗасызлык билгеләре булган транспорт чараларын исәпкә алу район Хакимияте тарафыннан ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын исәпкә алу журналына теркәлә (алга таба – исәпкә алу журналы).

Исәпкә алу журналының формасы район Хакимиятләре боерыгы белән раслана.

Ташландык яки хуҗасызлык билгеләре булган транспорт чарасын ачыклау факты исәпкә алу журналына ачыклаган көндә үк язып куела.

Журналга саклау өчен тапшырылган транспорт чарасының саклауга кабул итү датасы, саклауның нигезле булуы, кабаттан тикшерү датасы һәм акт саны күрсәтелгән мәгълүмат кертелә.

21. Район Хакимиятенең вазыйфаи затлары, ташландык (хуҗасыз) транспорт чарасын махсуслаштырылган транспорт чарасын кую урынына күчергән көнне үк, күчерү факты турында Яр Чаллы шәһәре буенча Эчке эшләр министрлыгы идарәсенә хәбәр итә.

## 5 бүлек. Транспорт чарасын саклау һәм бирү тәртибе

22. Күчерелгән транспорт чарасы махсуслаштырылган транспорт чарасын кую урынында өч ай буе саклана.

Өч ай тулганнан соң, шәһәр Башкарма комитеты ташландык транспорт чарасының бәйсез бәясен һәм техник торышына карап, базар бәясен билгеләү эшләрен тәэмин итә.

23. Ташландык транспорт чаралары Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган җир кишәрлекләрендә булып, аларның базар бәяләре «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә минималь хезмәт хакы күләменнән биш тапкыр артык суммадан ким билгеләнсә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге мөлкәтенә, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 226 нчы маддәсендә билгеләнгән тәртиптә, Башкарма комитет карары кабул итү юлы белән мөрәҗәгать итәләр.

24. Транспорт чарасының бәясе минималь хезмәт хакы күләменнән биш тапкыр күбрәк суммадан артып киткән очракта, әгәр милекче билгеле булмаса яки саклау срогы тулса, шәһәр Башкарма комитеты андый транспорт чарасын хуҗасыз дип тану һәм аңа муниципаль милек хокукын тану турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.

Транспорт чарасын хуҗасыз дип тану турындагы суд карары үз көченә кергәннән соң, күрсәтелгән транспорт чарасы билгеләнгән тәртиптә Яр

Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәт реестрына кертелә.

25. Транспорт чарасын хуҗасыз дип тану һәм аңа милек хокукын тану турында суд карары үз көченә кергән көннән алып, транспорт чарасының техник торышына бәйле рәвештә, шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан транспорт чарасын киләчәктә файдалану, реализацияләү яки аны утильләштерү турында карар кабул ителә.

26. Ташландык транспорт чарасы махсуслаштырылган куయю урынына күчерелгәннән һәм саклау срогы тулганнан соң, нинди дә булса зат әлеге транспорт чарасына дәгъвасын белдергән очракта, район Хакимиятенең транспорт чарасын бирүгә язмача рөхсәте булганда, махсуслаштырылган оешма тарафыннан транспорт чарасы махсуслаштырылган кую урыны территориясеннән әлеге затка бирелергә мөмкин.

Берәр зат транспорт чарасына дәгъва белән мөрәҗәгать иткән очракта, махсуслаштырылган оешманың җаваплы кешесе әлеге гражданны район Хакимиятенә җибәрергә тиеш.

27. Район Хакимиятенең транспорт чарасын бирүгә рөхсәте түбәндәге нигездә бирелә:

- әлеге зат тарафыннан куелган таләпләрнең законлылыгының раслануы (транспорт чарасына документлары күрсәтелгән яки мөрәҗәгать итүче затның транспорт чарасына, аннан файдалануга яки идарә итүгә хокукын раслаучы башка документ);

- махсуслаштырылган оешманың транспорт чарасын күчерү һәм саклау буенча чыгымнарны Башкарма комитетның махсуслаштырылган оешма белән төзелгән килешү шартлары нигезендәге бәяләр (тарифлар) буенча түләве.

Транспорт чарасын бирү турында журналда аны бирү вакытының датасын, кабул итеп алучы затны, аның шәхесен ачыклаган һәм транспорт чарасына хокукын раслаган, транспорт чарасының саклануы буенча дәгъвасын күрсәткән документлары турында язу язып куела.

Транспорт чарасын аның очен махсус билгеләнгән территориядән вакытлыча саклауга чыгару транспорт чарасы хуҗасының үз көче һәм средстволары белән башкарыла.

28. Транспорт чарасы хуҗасы аны күчерү һәм саклау белән бәйле чыгымнарны түләүдән баш тарткан очракта, тотылган чыгымнар суд аша эзләтеп алына.

## 6 бүлек. Хуҗасыз, ташландык транспорт чараларын утильләштерү

29. Хуҗасыз, шул исәптән ташландык транспорт чараларын утильләштерү махсуслаштырылган оешма тарафыннан утильләштерү хезмәте күрсәтү буенча килешү нигезендә башкарыла.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ташландык һәм хуҗасыз транспорт чараларын утильләштерү хезмәте күрсәтү буенча килешүнең заказчысы булып Башкарма комитет санала.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәрендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү Тәртибенә 1 нче кушымта

Транспорт чарасын тикшерү буенча
_____ АКТ

«___» _____________20__ ел _____ сәгать _____ минут

____________________________________________________________________________
_____________
(төзү урыны)

Комиссия составы: комиссия әгъзалары _______________________________
____________________________________________________________________________
_____________
(комиссия әгъзаларының вазыйфалары һәм Ф.И.А и.)
____________________________________________________________________________
_____________
транспорт чарасын билгеләде ____________________________________________
____________________________________________________________________________
_____________
(транспорт чарасының маркасы, төсе, моделе, дәүләти теркәлү билгесе (булганда)
____________________________________________________________________________
_____________

ташландык/хуҗасызлык билгеләре бар, шул сәбәпле, ____________________________________________
_____________
____________________________________________________________________________
_____________.
(транспорт чарасының торышы)

Кушымталар: ____________________________________________________________________.

Акт ____ данәдә төзелде.

Комиссия әгъзалары: ______________________

______________________ ______________________ (вазыйфа) (имза)

(Ф.И.А и.)

______________________ ______________________

______________________ (вазыйфа) (имза)

(Ф.И.А и.)

______________________ ______________________

______________________ (вазыйфа) (имза)

(Ф.И.А и.)

Яр Чаллы шәһәрендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү Тәртибенә 2 нче кушымта

Транспорт чарасы хуҗасына: маркасы, моделе

___________________________

дәүләти теркәлү билгесе (булганда) _______________

Транспорт чарасын күчерү таләбе

Сезгә шул хакта хәбәр итәм, Сезнең: _______________________________________________ адресы буенча торган транспорт чарасы гражданнар тормышына куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсуслаштырылган һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулык китерә, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм ишегалды территорияләрен һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган урыннарны җыештыруны кыенлаштыра.

Сезнең транспорт чарасы 20__ елның _____________ кадәр күчерелмәгән очракта, транспорт чарасын

_______________________________________________________________

_____________ тарафыннан расланган

(муниципаль норматив хокукый актның реквизитлары күрсәтелә)

Яр Чаллы шәһәрендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү Тәртибе нигезендә күчерү буенча чаралар күреләчәк.

Сезгә транспорт чарагызны күчерү чараларын күрергә яки шәхсән

______________________________________________________.

(вәкаләтле орган исеме күрсәтелә)

мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итәм.

Белешмә өчен телефон (нар): ______________________________.

Район Хакимияте Башлыгы ____________

____________________

(имза) (Ф.И.А и.)

Яр Чаллы шәһәрендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү Тәртибенә 3 нче кушымта

______________________________________
______
______________________________________
______ адресы буенча теркәлгән гражданин (ка)
___________________________
(Ф.И.А и.)

Транспорт чарасын күчерү турында таләп

Хөрмәтле ______________________!

Милек хокукында Сезгә түбәндәге транспорт чарасы карый:
Маркасы, моделе ____________________________________;
Идентификация саны (VIN) ___________________;
Җитештерелгән вакыты __________; житештергән оешма_________ ; (иле) _______________________; двигатель саны ___________________; шассие (рамасы) ________________; кузовы (кабинасы, прицепы) ________________; кузовның төсе (кабинаның, прицепның) _________________; теркәлү турындагы таныклыгы (серия саны) _______________, дәүләти теркәлү билгесе ______________, теркәлү датасы ______________, кем биргән (адресы) _________________________.

Күрсәтелгән транспорт чарасының түбәндәге ташландык билгеләре бар:
__________________________________________________________________________
_____________.
(билгеләрен күрсәтергә)

Сезгә:__________________________________________________________
_________________ тарафыннан расланган
(муниципаль норматив хокукый актның реквизитлары күрсәтелә)
гражданнар тормышына куркыныч тудыра, юл хәрәкәтенә, махсуслаштырылган һәм башка транспорт хәрәкәтенә комачаулык китерә, муниципаль берәмлек территориясен, юл челтәрен һәм иргегалды территорияләрен һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен бозып урнаштырылган

урыннарны жыештыруны кыенлаштыра торган транспорт чарагызны_______________ кадәр срокта махсус билгеләнгән урынга күчереп куярга тәкъдим итәм.

Сез ирекле рәвештә транспорт чарагызны күчереп куймаган очракта, ул ____________________________________________________________________
____________ адресы буенча урнашкан махсуслаштырылган куют урынына 20____ елның ______аенда ___ сәгать___ минутта мәжбүри рәвештә күчереләчәк.

Сез үзегезнең транспорт чарагызны махсуслаштырылган куют урыныннан үзегез мөстәкыйль рәвештә алырга бурычлы. Сез үзегезнең транспорт чарагызны махсуслаштырылган куют урыныннан алмаган очракта, Сезнең транспорт чарасы өч айга кадәр срокта саклаңачак. Транспорт чарасын махсуслаштырылган куют урынына күчергән моменттан алып өч ай тулганнан соң, Башкарма комитет транспорт чарасын хуҗасыз дип тану турында судка мөрәҗәгать итә.

Белешмә өчен телефон (нар): ______________________________.

Район Хакимияте Башлыгы ______________

______________________

(имза) (Ф.И.А н.)

Яр Чаллы шәһәрендә ташландык, хуҗасыз транспорт чараларын ачыклау, исәпкә алу, күчерү, саклау, утильләштерү Тәртибенә 4 нче кушымта

Транспорт чарасын кабат тикшерү буенча
____ АКТ

«___» ____________20__ ел _____ сәгать _____ минут

______________________________________________________________

____________
(төзү урыны)

Комиссия составы: ______________________________

______________________________________________________________

___________
(комиссия әгъзаларының вазыйфалары һәм Ф.И.А и.)

______________________________________________________________

махсуслаштырылгын оешма катнашында______________________________

______________________________________________________________

___________
(транспорт чарасын тикшерүдә катнашучыларның Ф.И.А и.)
транспорт чарасын билгеләде

______________________________________________

______________________________________________________________

____________
(транспорт чарасының маркасы, төсе, моделе, дәүләти теркәлү билгесе (булганда)

______________________________________________________________

____________
милек хокукындагы______________________________________________
(транспорт чарасы хуҗасының Ф.И.А и. – әгәр ул билгеле булса)
ташландык/хуҗасызлык билгеләре бар, шул сәбәпле, каралган транспорт чарасы таләп буенча күчерелмәгән.___________________________________________

____________________
(транспорт чарасының торышы, шул исәптән, аны ташландык/хуҗасызларга кертү билгеләре)

______________________________________________________________

Башкарма комитет тарафыннан ташландык яки хуҗасыз транспорт чарасын күчерү турында карар кабул ителде (Башкарма комитетның ____________ карары).

Шул сәбәпле, комиссия транспорт чарасын җаваплы саклауга махсуслаштырылган оешманың түбәндәге адрес буенча урнашкан махсуслаштырылган куюю урынына тапшыра: ____________________________________________

Кушымталар:
1. Фототаблица - _____ биттә ______.сурәт;
2.________________
3.________________

Район Хакимиятендә саклана торган акт бер данәдә төзелде.

Комиссия әгъзалары:

______________________ ________________ ______________________________
(вазыйфа) _____________ (имза) ____________ (Ф.И.А и.)

______________________ ________________ ______________________________
(вазыйфа) _____________ (имза) ____________ (Ф.И.А и.)

______________________ ________________ ______________________________
(вазыйфа) _____________ (имза) ____________ (Ф.И.А и.)

Транспорт чарасын тикшерүдә катнашкан башка затлар:

______________________ ________________ ______________________________
(вазыйфа) _____________ (имза) ____________ (Ф.И.А и.)

______________________ ________________ ______________________________
(вазыйфа) _____________ (имза) ____________ (Ф.И.А и.)